**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
_______________ № ___

Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, район Уставына, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык алдында ачык тыңлаулар уздырырга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. «Актаныш таңнары» газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырып чыгарырга.
4. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көн дип билгеләргә.

- ачык тыңлаулар уздыру вакыты - 2023 елның 04 декабре:

-үткәрү урыны: 10.00 сәгатьтә, Уразай авылы, Уразай авыл мәдәният йорты, Үзәк ур., 4 нче йорт;

-үткәрү урыны: 12.00 сәгатьтә, Илчебай авылы, Илчебай авыл клубы, Үзәк ур., 19 нчы йорт;

-үткәрү урыны: 14.00 сәгатьтә, Куян авылы, «Куян авылы мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе (Куян авылы,Үзәк ур., 57 йорт);

-үткәрү урыны: 16.00 сәгатьтә, Шәрип авылы, Шәрип авылы мәдәният йорты, Үзәк ур., 4 нче йорт;

-үткәрелү урыны: 18.00 сәгатьтә, Мерәс авылы, Мерәс авыл клубы., Үзәк ур., 35а.й.

5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы - А.К.Галиәхмәтовны ачык тыңлаулар уздыру өчен җаваплы дип билгеләргә.
6. Уразай авыл җирлеге генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
____________ 2023 ел, №___
кушымта

Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге Тәртип Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатыннан эшләнде (алга таба Генераль план) һәм авыл җирлеге гражданнарының Генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук Генераль план проекты буенча халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Генераль план проекты буенча гражданнарның фикер алышуда катнашуы халыкның Генераль план проекты буенча ачык тыңлауларда катнашуы һәм авыл җирлегендә яшәүчеләрнең язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирлекнең генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дш.- җм.- 9.00 - 16:00 гә кадәр,  (төшке аш 11.30 - 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында fgis.economy.gov.ru мәҗбүри бастырылып чыгарылырга тиеш.

5. Җирлекнең генераль планы проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: 423740, ТР, Актаныш ав., Ленин пр., 17 й., Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктур үсеш бүлеге;

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү, шулай ук Генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлауларны үткәрү өчен җаваплы кеше башкара.

Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документаль тәэмин итүне ачык тыңлаулар секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы, секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү үткәрелә. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан да артык бирелми;
- җирлекнең Генераль планы проектын тикшерү буенча чыгышлар өчен 3 минуттан артык түгел;

- репликалар һәм кисәтүләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

11. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан Генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәне ачык тыңлауларны оештыручы һәм секретаре имзалый.

12. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырган көннән соң, 2 көн эчендә, ачык тыңлаулар йомгаклары буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләнең атамасы;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

14. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы имза сала һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Актаныш таңнары» газетасында, районның рәсми сайтында, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында мәҗбүри бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.